Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Бәтке поселогы **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«5» декабрь 2022 ел № 9

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Бәтке» авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2022 елда яшәү урыны буенча Бәтке авыл җирлеге Бәтке поселогы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Гагарин, Үзәк, Яңа Бәтке авыллары буенча күпфатирлы йортларның якын-тирә территорияләрен төзекләндерү (таш сатып алу, ташу, асфальт валчык салу)
- Бәтке авылының канализация системасын ремонтлау
- «Яшел утрау» паркы территориясен төзекләндерү (газон чабу, сәхнәне буяу, эскәмияләр)
- Бәтке авылы юлларын ремонтлау
- Бәтке авылының Үзәк урамындагы тротуарны төзекләндерү эшләрен башкару
- Колхоз урамы буенча территорияне төзекләндерү (грунт кертү, яшелләндерү)
- Бәтке авылы чишмәсен төзекләндерү
- Бәтке авылында урам утларын сатып алу һәм урнаштыру
- Бәтке авылында балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру

2. Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Бәтке поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Бәтке поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы В.А.Валиева